РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Кармалинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Кармалы авыл җирлеге
Башлыгы

423598, Нижнекамский район,
с. Кармалы,ул. Пионерская,1

423598, Түбән Кама районы,
Кармалы авылы,Пионер урамы, 1

тел./факс (8555) 33-39-17, электронный адрес: Karmalinskoe.sp@tatar.ru, сайт: www.karmalinskoe-sp.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.06.2022 ел № 5

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлегенә кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маенда кабул ителгән 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендә кабул ителгән 273-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маенда кабул ителгән 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кармалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлегенә кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүнең кушымта итеп бирелгән тәртибен расларга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

А.Д. Кубышкин

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге Башлыгының 2022 елның 30 июнендәге 5 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлегенә кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Кармалы авыл җирлегенә (алга таба – авыл җирлеге) кергән коррупция фактлары буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карауның үзенчәлекләрен билгели, ул үз эченә коррупция һәм янап акча алу, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен кысрыклау, хезмәт тәртибенә карата таләпләрне бозу, шулай ук авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре, шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм авыл җирлеге эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләр тарафыннан кылынган хезмәт урыныннан явызларча файдалану билгеләре булган башка гамәлләр (алга таба - мөрәҗәгать) турында мәгълүматны ала.

Башка затларга карата шундый ук фактлар турында белешмәләр булган мөрәҗәгать, «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында»2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 3 өлеше нигезендә, мөрәҗәгатьләрдә куелган мәсьәләләрне хәл итү аларның компетенциясенә кергән тиешле органга яисә тиешле вазыйфаи затка җибәрелергә тиеш.

2. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча эшнең хокукый нигезен тәшкил итә:

- «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендә кабул ителгән 273-ФЗ номерлы Федераль закон;

- «Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маенда кабул ителгән 59-ФЗ номерлы Федераль закон

- «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маенда кабул ителгән 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

3. Мөрәҗәгать «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында»Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлә һәм карала.

Мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, эшләнә торган яки кылынган хокукка каршы эш турында, шулай ук аны әзерли торган, эшли торган яки кылган зат турында белешмәләр булганда, мөрәҗәгать аларның компетенциясе нигезендә хокук саклау органнарына җибәрелергә тиеш.

4. Мөрәҗәгатьне караганда, мөрәҗәгатьтәге мәгълүматларны, шулай ук гражданның шәхси тормышына кагылышлы мәгълүматларны аның ризалыгыннан башка ачып салу рөхсәт ителми. Карала торган мәсьәләнең барлык шартларын

ачыклауга кадәр мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтенә ия булган вазыйфаи затка язма мөрәҗәгать җибәрүмөрәҗәгатьтәге мәгълүматларны тарату булып тормый,

5. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт мәгълүматларының һәм конфиденциаль характердагы белешмәләрнең сакланышы өчен җаваплы.

6. Билгеләнгән тәртиптә теркәлгән мөрәҗәгатьләр Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Советының эш башкару һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлегенә хезмәт (вазыйфа) тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссиядә карау өчен тапшырыла.

7. Мөрәҗәгать җибәргән гражданга җавап әзерләү авыл җирлегенең җаваплы заты тарафыннан башкарыла.

8. Әгәр мөрәҗәгатьтә җаваплы затка карата коррупция юнәлешендәге фактлар турында белешмәләр булса, соңгысы, үзенә үзе отвод биреп, аны карауда катнашмый. Мондый мөрәҗәгатьне карау Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Советының эш башкару һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге тарафыннан башкарыла.

9. Авыл җирлегенең гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан, коррупция юнәлешендәге фактларны тудыручы сәбәпләрне үз вакытында ачыклау һәм бетерү максатыннан, гражданнарның коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьләре системалы (елына 1 тапкырдан да ким булмаган) рәвештә анализлана һәм гомумиләштерелә.